Капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турында
ХӘБӘР ИТҮ

Әлеге хокукый акт проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар башлануы турында хәбәр итәбез: «Кадастр номеры 16:15:121001:2375 булган җир кишәрлегенең капиталь төзелеш объектларын төзүнең рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында:

- җир кишәрлеге чикләреннән минималь чигенүләрне 4 нче ноктадан 5 нче ноктага кадәр киметү өлешендә (Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының 02.04.2025нче елгы 22/п номерлы карары нигезендә).

Проект буенча иҗтимагый фикер алышуларны үткәрү тәртибе һәм сроклары: 04.04.2025 елдан башлап 23.04.2025 елга кадәр.

Иҗтимагый фикер алышулар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда, Югары Ослан муниципаль берәмлеге Уставында билгеләнгән тәртип, Татарстан Республикасы Югары Ослан район Советының 2020 елның 04 июнендәге 58-670 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге проект буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмә нигезендә уздырыла.

Иҗтимагый фикер алышуларда катнашучылар даирәсе: кызыксынучы затлар.

Иҗтимагый фикер алышулар уздырыла торган Территория: Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Яр буе Морквашы авыл җирлеге.

Иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проект экспозициясен ачу урыны һәм датасы: 04.04.2025 елдан мәгълүмат стендларында:

- Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты, түбәндәге адрес буенча: 422570, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Югары Ослан авылы, Чехов ур., 18 йорт;
- Яр буе Морквашы авыл җирлеге Башкарма комитеты: 422570, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, 422594, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Яр буе Морквашы авылы, Красавин ур., 62 й. адресы буенча

Проект экспозициясен үткәрү сроклары: 04.04.2025 елдан алып 23.04.2025 елга кадәр.

Экспозициядә булу мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат: дүш. - җомга 09-00 с. - 16-00 с.

Җәмәгать фикер алышуларында катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше: Проектның 04.04.2025 елдан 2025 елның 23 апреленә кадәр барлык чор дәвамында Югары Ослан районыhttp://verhniy-uslon.tatarstan.ru/ битендә җәмәгать фикер алышуларында каралырга тиешле, «Архитектура һәм шәһәр төзелеше» вкладкасында, экспозиция уздыруда, идентификация үткән иҗтимагый фикер алышуда катнашучылар әлеге проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

1) рәсми сайт ярдәмендә;

2) иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы - Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль берәмлегендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге проектлар буенча даими эшләүче комиссия адресына (адресы буенча: Татарстан Республикасы, Югары Ослан ав., Чехов ур., 18, тел: 8(84379) 2-16-59;
3) проектта экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу журналында: «Капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турында» дигән проект буенча экспозиция күрсәтелеп.

Җәмәгать фикер алышуларында каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт һәм аңа мәгълүмати материаллар, яисә мондый проект урнаштырылачак һәм аңа мәгълүмати материаллар кулланып җәмәгать фикер алышулары уздырылачак мәгълүмати системалар турында мәгълүмат: Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: https://pravo.tatarstan.ru һәм Югары Ослан муниципаль районысайтында:https://verhniy-uslon.tatarstan.ru.

Иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт һәм аңа карата мәгълүмати материаллар: Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайты: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru

Әлеге хәбәрне бастырып чыгарырга: 04.04.2025 елдан соң Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: https://pravo.tatarstan.ru һәм Югары Ослан муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге сайтында: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru урнаштырырга.

Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.А. Ахметшин